**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Березняк авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**12 ноябрь, 2025** **№ 3**

**«Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Камышлы авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районының Березняк авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 25 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Камышлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын түбәндәге адреста урнашкан башлангыч мәктәп бинасында үткәрергә: Камышлы авылы, Ленин урамы, 14 йорт.

2. 2025 елның 25 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Камышлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын түбәндәге адреста урнашкан башлангыч мәктәп бинасында үткәрергә: Камышлы авылы, Ленин урамы, 14 йорт.

3. 2025 елның 25 ноябрендә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Камышлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын түбәндәге адреста урнашкан башлангыч мәктәп бинасында үткәрергә: Камышлы авылы, Ленин урамы, 14 йорт.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Камышлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлар); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләрдән; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны

чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүлергә.

6. Березняк авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Березняк авыл җирлеге башлыгы: Р.Ф. Шәрипов